КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 31 октябрь г.Казань № 950

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет кредитлары буенча Татарстан Республикасы алдындагы йөкләмәләренә (бурычларына) реструктуризация үткәрү кагыйдәләрен раслау хакында» 2013 ел, 15 февраль, 106 нчы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет кредитлары буенча Татарстан Республикасы алдындагы йөкләмәләренә (бурычларына) реструктуризация үткәрү кагыйдәләренә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет кредитлары буенча Татарстан Республикасы алдындагы йөкләмәләренә (бурычларына) реструктуризация үткәрү кагыйдәләрен раслау хакында» 2013 ел, 15 февраль, 106 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 27 ноябрь, 1137 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет кредитлары буенча Татарстан Республикасы алдындагы йөкләмәләренә (бурычларына) реструктуризация үткәрү кагыйдәләренә, түбәндәге эчтәлекле $15^1$ пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«$15^1$. Бу Кагыйдәләрнең 2 пункты нигезендә бюджет кредиты буенча реструктуризацияләнгән бурычларны каплау чоры 2024 елда бурычлы оешма гаризасы нигезендә 2028 елдан 2037 елга (2037 елны кертеп) кадәрге чорга ел саен тигез өлешләр белән түләү һәм әлеге бурычларны вакытыннан алда түләү мөмкинлеге белән күчерелергә тиеш.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин